КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 5 декабрь г.Казань № 1556

2024 – 2026 елларга «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтләрен күрсәтүне финанслауның җан башына нормативларын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 14 ноябрь, 1208 нче карары белән расланган 2022 – 2026 елларга Татарстан Республикасында аутизм спектрындагы бозылулары һәм башка менталь бозылышлары булган кешеләргә комплекслы булышлык күрсәтеп тору концепциясен тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

2024 – 2026 елларга «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнар бер хезмәт өчен 40 272,64 сум күләмендә;

2024 – 2026 елларга «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтен күрсәтүгә финанслауның җан башына нормативы бер хезмәт өчен 40 272,64 сумга тигез.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтләрен күрсәтүне финанслауның җан башына нормативларын исәпләү тәртибен һәм 2023 елга «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм «Эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтләрен күрсәтүне финанслауның җан башына нормативларын раслау турында" 2023 ел, 7 август, 948 нче карарының 1 пунктындагы өченче абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин